**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 октябрь № 827

г. Казань

Казан шәһәренең «5 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен һәм Казан шәһәренең «Медицина университеты клиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен үзгәртеп оештыру турында

Татарстан Республикасында дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләре белән идарә итүне оптимальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәренең «5 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен Казан шәһәренең «Медицина университеты клиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә (алга таба – Учреждение) кушу юлы белән, соңгысы эшчәнлегенең төп максатларын саклап, Казан шәһәре, Ш.Камал урамы, 12 нче йорт адресы буенча урнашкан Казан шәһәренең «5 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен һәм Казан шәһәре, Толстой урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан Казан шәһәренең «Медицина университеты клиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен үзгәртеп оештыру турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының тәкъдимен кабул итәргә.

2. Учреждение эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасында тиешле финанс елына һәм план чорына әлеге максатларга күздә тотылган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

Учреждениене гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкарырга;

әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән оешмаларны үзгәртеп оештыруга бәйле законнар белән күздә тотылган чаралар үткәрүне тәэмин итәргә;

үзгәртеп оештыру чаралары нәтиҗәсендә эшләреннән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне законнар нигезендә тәэмин итәргә;

ел саен Уставы белән күздә тотылган төп эшчәнлеге нигезендә Учреждениегә дәүләт йөкләмәсен расларга.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Учреждение уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алганнан соң 30 көн эчендә оператив идарә хокукында дәүләт мөлкәтен, шул исәптән аеруча кыйммәткә ия, Казан шәһәренең «5 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә элек оператив идарә хокукында беркетелгән мөлкәтне Учреждениегә беркетергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков